**СОВЕТ СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп урамы, 9а

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 апрель 2018 ел № 106

**Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советының 2016 елның 4 октябрендә кабул ителгән 51 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ, «Конкуренцияне яклау турында» 26.07.2006 ел, № 135-ФЗ, Суыксу авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советының 2016 елның 5 октябрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә, шулай ук күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару һәм 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль законда каралган күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләр бирү нигезендә, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, мондый исәпкә алынырга тиешле күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастр исәбен алып бару турында " 13.07.2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон нигезендә, шулай ук күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару.»;

1.2. 12 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә шартнамәләрен, хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән муниципаль милекне ияләү һәм (яки) файдалану хокукын күздә тотучы башка шартнамәләрне төзү «Көндәшлекне яклау турында»26.07.2006 ел, № 135-ФЗ Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев